**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Зур Сәрдек авыл җирлеге Башлыгы**
**карары**

**12ноябрь 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылында***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Купка авылы, Пролетарская урамы, 1а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 23 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылында***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Купка авылы, Пролетарская урамы, 1а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раславга: «Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Купка авылы урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Купка авылында урам юл челтәрен карап тоту;

- Купка авылы чишмәсен төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- урам утларын җайга салу өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу.

- Купка авылына керү һәм чыгу урыннарында видеокамералар урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы: Ф. М. Фәттахов.

ОГРН 1021607753232

ИНН 1623001727